ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Гоголя, д.1, с.Акбаш, 423958

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКБАШ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Гоголь урамы, 1 йорт, Акбаш авылы, 423958

Тел./факс: (85593) 4-14-34, e-mail: Akbash.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№15 15 сентября 2020 г.

2020 елның 28 маендагы Акбаш авыл җирлеге башлыгының 11 санлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе турында»

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы, 2006 елның 2 маендагы «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 59-ФЗ санлы Федераль законнар, 2003 елның 12 маендагы «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 16-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 4 бүлектә «ел саен» сүзен «һәрдаим» (әмма елына бер тапкырдан да ким булмаган күләмдә) дип алмаштырырга;

- 5 һәм 8 бүлекләрдә «хисап чорыннан соң килүче» сүзләрен «киләсе хисап елы» дигән сүзләргә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Акбаш авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы: Л.Р.Синагатуллина